**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
16.05.2020

КАРАР
№ПР-95

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы ачык сулыкларда 2020 елгы су коену сезоны чорында су коенуны тыю турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының "Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 15.05.2020 елның, 8-20 номерлы карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы территориясендә пляжлар һәм сулыкларда массакүләм ял итү урыннары булмау сәбәпле,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген саклау максатларында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан ачык сулыкларда гражданнарга 2020 елгы су коену сезоны чорында коенуны тыярга.

2. 2020 елгы су коену сезоны чорында Актаныш муниципаль районының су объектлары янында халык күпләп ял итә торган урыннарда профилактик рейдлар өчен мобиль төркем составын расларга (1 нче кушымта).

3. Авыл башкарма комитетлары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда коенуны тыю һәм балаларны махсус контрольдә тоту кирәклегетурында халык белән белешмәлекләр өләшеп, аңлату эшләре алып барырга;
- балаларның олылар тарафыннан караучысыз һәм күзәтүсез булган гаиләләрне аерым контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән индивидуаль профилактик эш алып барырга, ата-аналарга имза куйдырып, коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга;
- ачык сулыкларда коенуны тыю турында аншлаглар урнаштырырга;

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
16.05.2020 ел, № ПР-95
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районында 2020 елгы су коену сезоны чорында халык күплəп ял итə торган су объектлары янында профилактик рейдлар өчен мобиль төркемнəр составы

| | |
|---|---|
| Мирзаянова А.Р. | Актаныш муниципаль районының административ комиссиясе секретаре, башкарма комитетның мобиль патруль төркеменең эшен тикшереп тору өчен җаваплы вазыйфаи заты; |
| Шəрифҗанов И.И | Актаныш янгын сүндерү һəм коткару гарнизоны башлыгы (килешү буенча); |
| Хəйретдинов И.И. | Россия Эчке эшлəр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Хəева-Хəмитҗанова В.Х. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мəгариф идарəсе" МКУ башлыгы (килешү буенча); |
| Нургалиев И.И. | Актаныш муниципаль районының «ОСВОД» РОО җитəкчесе (килешү буенча); |
| Хөсəенов Р.В. | Актаныш муниципаль районы гражданлык яклау идарəсе" МКУ җитəкчесе; |
| Актаныш муниципаль районы авыл җирлеклəре башлыклары (килешү буенча); | |